МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

16.09.2020 г.Казань № 633

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2020 елның 6 октяберендә 6875 номеры белән теркәлде

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2017 елның 13 февралендәге 74 номерлы «2017-2020 елларда тәрбиягә алучы гаилә төзергә теләгән өлкән яшьтәге гражданны һәм кандидатны психологик әзерләү тәртибен раслау турында» боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

Боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2017 елның 13 февралендәге 74 номерлы «2017-2020 елларда тәрбиягә алучы гаилә төзергә теләгән өлкән яшьтәге гражданны һәм кандидатны психологик әзерләү тәртибен раслау турында» боерыгына кертелә торган кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2018 елның 10 гыйнварындагы 3 номерлы боерыгы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән).

2. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.

Министр Э.А.Зарипова

Расланган Татарстан
Республикасы Хезмәт, халыкны
эш белән тәэмин итү һәм
социаль яклау министрлыгының
16.09.2020 ел. № 633 боерыгы
белән

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2017 елның 13 февралендәге 74 номерлы боерыгына кертелә торган үзгәрешләр
«2017-2020 елларда тәрбиягә алучы гаилә төзергә теләгән өлкән яшьтәге гражданны һәм кандидатны психологик әзерләү тәртибен раслау турында»

Исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Тәрбиягә алучы гаилә төзергә теләгән өлкән яшьтәге гражданны һәм кандидатны психологик әзерләү тәртибен раслау турында»

преамбуладагы «Өлкән кеше өчен тәрбиягә алучы гаилә» пилот проектын гамәлгә ашыру турында» сүзләрен «Өлкән яшьтәге, социаль хезмәт күрсәтүнең стационар рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәтүгә мохтаж дип танылган, эшкә яраксыз гражданнар өчен тәрбиягә алучы гаиләләр төзү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмәне раслау хакында» сүзләренә алмаштырырга;

1 пункттагы «2017-2020 елларда» сүзләрен төшереп калдырырга;

Боерык белән расланган 2017-2020 елларда өлкән яшьтәге гражданны һәм тәрбиягә алучы гаилә төзергә теләүче кандидатны психологик әзерләү тәртибендә (алга таба - Тәртип):

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Тәрбиягә алучы гаилә төзергә теләгән өлкән яшьтәге гражданны һәм кандидатны психологик әзерләү тәртибе»

Тәртипнең 1 пунктында «2017-2020 елларда» сүзләрен төшереп калдырырга, «Өлкән кеше өчен тәрбиягә алучы гаилә» пилот проектын гамәлгә ашыру турында» сүзләрен «Өлкән яшьтәге, социаль хезмәт күрсәтүнең стационар рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәтүгә мохтаж дип танылган, эшкә яраксыз гражданнар өчен тәрбиягә алучы гаиләләр төзү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмәне раслау хакында» сүзләренә алмаштырырга;

Тәртипкә 1 нче кушымтада:

нумерацияле исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Тәрбиягә алучы гаилә төзергә теләгән өлкән яшьтәге гражданны һәм кандидатны психологик әзерләү тәртибенә 1 нче кушымта»;

«__» _________ 201_ ел дан «__» __________ 201_ ел га кадәр» сүзләрен «__» _________ 20_ ел дан «__» __________ 20_ ел га кадәр» сүзләренә алмаштырырга;

Тәртипкә 2 нче кушымтада нумерацияле исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Тәрбиягә алучы гаилә төзергә теләгән өлкән яшьтәге гражданны һәм кандидатны психологик әзерләү тәртибенә 2 нче кушымта»;